**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БОЕРГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ ҮЗИДАРӘСЕ**

# КАРАР

18 март 2025 ел № 59/1

2024 ел өчен Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап проекты буенча халык тыңлауларын үткәрү хакында

Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге халкының «2024 ел өчен Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап» хакында карар проекты буенча фикер алышуда катнашу хокукларын саклау максатыннан Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлегендә халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә таянып

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «2024 ел өчен Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап» хакында Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Советы карар проекты буенча халык тыңлауларын үткәрергә.

2. Әлеге карарны авыл җирлегендә мәгълүмати стендларда һәм Тукай муниципаль районның рәсми сайтында 2025 елның 19 мартыннан да соңга калмыйча урнаштырырга.

3. Билгеләргә

- үткәрү срогын – 1 көн;
- үткәрү вакытын – 2025 елның 28 мартында 10.00 сәгатьтә;
- үткәрү урынын – Боерган авылы, Тынычлык урамы, 64Б йорт (Боерган авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасы);
- фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тәкъдим итү, чыгыш хокукы белән халык тыңлауларында катнашу өчен гаризалар бирү адресы – Боерган авылы, Тынычлык урамы, 64Б йорт (8552) 377823) телефоны буенча (эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатька кадәр);
- чыгыш ясау хокукы белән халык тыңлауларында катнашу өчен гаризалар бирү вакыты – 2025 елның 27 мартына кадәр.

4. Түбәндәге составта оештыру эшләре комитеты төзергә:

-Минакова Гөлүзә Гаязовна – Боерган авыл җирлегенең Башкарма комитет җитәкчесе:
- Шайхразиев Фәнис Вәзифович – бюджет, салымнар һәм иктисадый сәясәт буенча даими комиссия рәисе;
- Камилҗанов Зарифҗан Мәхмүтович - бюджет, салымнар һәм иктисадый сәясәт буенча даими комиссия әгъзасы;

5. Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Башкарма комитетына билгеләнгән тәртип нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда «2024 ел өчен Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап» хакында карар проекты буенча халык тыңлауларын әзерләргә һәм үткәрергә.

6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны кануннар, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссия әгъзаларына тапшырам.

Боерган авыл җирлеге Башлыгы Г.Г.Минакова